КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 18 декабрь г.Казань № 1162

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Сәнәгать (индустриаль) паркларының һәм технопаркларның җитештерү һәм инновация компанияләрен булдыру (үстерү) максатларында, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына җитештерү мәйданнарыннан һәм урыннарыннан ташламалы файдалана алу мөмкинлеге бирүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен сәнәгать (индустриаль) паркларының һәм (яки) технопаркларның идарә итүче компанияләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2019 ел, 4 июль, 548 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Сәнәгать (индустриаль) паркларының һәм технопаркларның җитештерү һәм инновация компанияләрен булдыру (үстерү) максатларында, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына җитештерү мәйданнарыннан һәм урыннарыннан ташламалы файдалана алу мөмкинлеге бирүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен сәнәгать (индустриаль) паркларының һәм (яки) технопаркларның идарә итүче компанияләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2019 ел, 4 июль, 548 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «2018 – 2021 елларга» сүзләрен – «2018 – 2024 елларга» сүзләренә алыштырырга, «2014 – 2021 елларга» сүзләрен «2014 – 2024 елларга» сүзләренә алыштырырга;

әлеге карар белән расланган Сәнәгать (индустриаль) паркларының һәм технопаркларның җитештерү һәм инновация компанияләрен булдыру (үстерү) максатларында, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына җитештерү мәйданнарыннан һәм урыннарыннан ташламалы файдалана алу мөмкинлеге бирүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен сәнәгать (индустриаль) паркларының һәм (яки) технопаркларның идарә итүче компанияләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә:

1 нче пунктта «2014 – 2021 елларга» сүзләрен «2014 – 2024 елларга» сүзләренә алыштырырга, «2018 – 2021 елларга» сүзләрен «2018 – 2024 елларга» сүзләренә алыштырырга;

3 нче пунктта «2014 – 2021 елларга» сүзләрен «2014 – 2024 елларга» сүзләренә алыштырырга, «2018 – 2021 елларга» сүзләрен «2018 – 2024 елларга» сүзләренә алыштырырга;

5 нче пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«үзгәртеп оештыру, бетерелү процессында булмаска, аларга карата банкротлык процедурасы башланмаска, сәнәгать (индустриаль) паркы һәм (яки) технопаркларның идарә итүче компанияләре эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган тәртиптә туктатылмаска;»;

7 нче пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«үзгәртеп оештыру, бетерелү процессында булмау, аларга карата банкротлык процедурасы башланмау, сәнәгать (индустриаль) паркы һәм (яки) технопаркларның идарә итүче компанияләре эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган тәртиптә туктатылмау;»;

12 нче пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия бирү нәтиҗәләре һәм аларның мәгънәләре;»;

12 нче пунктның унөченче абзацында «нәтиҗәлелек күрсәткечләренә ирешү турында һәм объектлар төзү һәм (яки) реконструкцияләү буенча чараларны башкару графигын үтәү турында хисап документлары» сүзләрен «субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турында хисап һәм объектларны төзү һәм (яки) реконструкцияләү буенча чараларны башкару графигын үтәү турында хисап» сүзләренә алыштырырга;

13 нче пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Субсидия бирү нәтиҗәләре:»;

17 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17. Сәнәгать (индустриаль) паркының һәм (яки) технопаркның идарә итүче компаниясе Министрлыкка түбәндәге хисапларны тапшыра:

хисап кварталыннан соң килүче айның 5енә кадәр бу Тәртипкә теркәлгән 1 нче кушымтадагы форма буенча эшләрне финанслау, башкару графигын үтәү турында хисап;

хисап кварталыннан соң килүче айның 5енә кадәр бу Тәртипкә теркәлгән 2 нче кушымтадагы форма буенча объектлар төзү һәм (яки) реконструкцияләү буенча чараларны башкару графигын үтәү турында хисап;

субсидия бирелә торган хисап елыннан соң килүче елның бишенче эш көненнән дә соңга калмыйча, бу Тәртипкә теркәлгән 3 нче кушымта нигезендәге форма буенча субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында хисап;

субсидия бирелә торган хисап елыннан соң килүче елның бишенче эш көненнән дә соңга калмыйча, бу Тәртипкә теркәлгән 4 нче кушымта нигезендәге форма буенча, түбәндәге документларны теркәп, аларның финанслар белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнар турында хисап:

бу Тәртипнең 4 нче пунктында күрсәтелгән максатларга юнәлдерелгән чыгымнарны раслый торган документларның күчермәләре (эшләрне тапшыру-кабул итү актлары күчермәләре, товар-транспорт йөкнамәләре, счет-фактуралар, шартнамәләр);

КС-3 формасы буенча сәнәгать (индустриаль) паркын һәм (яки) технопаркны төзү һәм (яки) үстерүгә чыгымнар һәм башкарылган эшләр кыйммәте турында белешмә кәгазьләре күчермәләре;

КС-2 формасы буенча сәнәгать (индустриаль) паркын һәм (яки) технопаркны төзү һәм (яки) үстерүгә башкарылган эшләрне кабул итү турында актлар күчермәләре;

дәүләт төзелеш күзәтчелеге органының төзелгән, реконструкция ясалган капиталь төзелеш объектының техник регламентлар һәм проект документлары таләпләренә, шул исәптән энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренә һәм капиталь төзелеш объектының кулланыла торган энергетика ресурсларын исәпкә алу җайланмалары белән тәэмин ителешенә карата таләпләргә туры килү-килмәве турындагы бәяләмәләр күчермәләре;

башкарылган эшләр өчен түләүне раслый торган түләү документлары күчермәләре;

субсидияләр бирү нәтиҗәсенә ирешүне раслый торган башка документлар.

Әгәр дә сәнәгать (индустриаль) паркының һәм (яки) технопаркның идарә итүче компаниясе субсидия бирү турындагы килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешмәгән очракта, Министрлык тарафыннан штраф санкцияләре кулланыла. Әлеге очракта, штраф санкцияләренең күләме түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$A = \left( \sum_{i=1}^{6} \left( 1 - \frac{d_i}{D_i} \right) \times X \right) \times V,$$

монда:

A – штраф санкцияләренең күләме;

i – субсидия бирү турындагы килешүдә күрсәтелгән субсидия бирү нәтиҗәләре саны;

$d_i$ – субсидия бирү турындагы килешүдә күрсәтелгән субсидия бирүнең i-нәтиҗәсенең ирешелгән мәгънәсе;

$D_i$ – субсидия бирү турындагы килешүдә күрсәтелгән субсидия бирүнең i-нәтиҗәсенең план буенча мәгънәсе;

X – хисап чорының соңгы көне хәленә карата Россия Федерациясе Үзәк банкындагы төп ставканың $\frac{1}{300}$ тигез булган төзәтү коэффициенты;

V – сәнәгать (индустриаль) паркының һәм (яки) технопаркның идарә итүче компаниясе тарафыннан алынган субсидия акчасының күләме.

Әгәр дә субсидия бирү нәтиҗәләренең берсен исәпләгәндә факттагы күрсәткеч план буенча күрсәткечтән артып китсә, бу күрсәткеч буенча $\left(1-\frac{d_i}{D_i}\right)$ формуланың мәгънәсе нульгә тигез итеп алына.»;

20 нче пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«хисап чоры тәмамлану вакытына субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешмәгәндә.»;

әлеге Тәртипкә 1, 2, 3, 4 нче кушымталар (карарга теркәләләр) өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Сәнәгать (индустриаль) паркларының һәм технопаркларның җитештерү һәм инновация компанияләрен булдыру (үстерү) максатларында, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына җитештерү мәйданнарыннан һәм урыннарыннан ташламалы файдалана алу мөмкинлеге бирүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен сәнәгать (индустриаль) паркларының һәм (яки) технопаркларның идарә итүче компанияләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә
1 нче кушымта

Форма

Эшләрне финанслау, башкару графигын үтәү турында
хисап

(ӨКС белән сум)

| Т/с | Эш исеме | ____ елның гыйнвары | | ____ елның феврале | | … | | ____ елның декабре | | ____ ел өчен барлыгы | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | план | факт | план | факт | план | факт | план | факт | план | факт |
| 1. | | | | | | | | | | | |
| 2. | | | | | | | | | | | |
| … | | | | | | | | | | | |
| | Барлыгы | | | | | | | | | | |
| | Финанслау чыганаклары: | | | | | | | | | | |
| | бюджеттан тыш (шәхси) чыганаклар | | | | | | | | | | |
| | Татарстан Республикасы бюджеты | | | | | | | | | | |
| | федераль бюджет | | | | | | | | | | |

Җитәкчесе ______________________ ______________________ ________________________________
(вазыйфасы) (имзасы) (имзасын тутырып язу)

20___ ел, «___»________________

Сәнәгать (индустриаль) паркларының һәм технопаркларның җитештерү һәм инновация компанияләрен булдыру (үстерү) максатларында, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына җитештерү мәйданнарыннан һәм урыннарыннан ташламалы файдалана алу мөмкинлеге бирүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен сәнәгать (индустриаль) паркларының һәм (яки) технопаркларның идарә итүче компанияләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә 2 нче кушымта

Форма

## Объектларны төзү һәм (яки) реконструкцияләү буенча чараларны башкару графигын үтәү турында хисап

<table>
<tr><td rowspan="4">Т/с</td><td rowspan="4">Капиталь төзелеш объектының исеме (төзелеш адресы)</td><td rowspan="4">Төзелеш төре (төзелеш, реконструкция, техник яктан яңадан җиһазландыру)</td><td colspan="15">Капиталь төзелеш объектларын төзүгә (реконструкцияләүгә, шул исәптән реставрация элементлары, техник җиһазландыру белән) каралган акчалар күләме, мең сум</td><td colspan="2" rowspan="3">Җир бүлеп бирү</td><td rowspan="3">Проектлаштыру</td><td rowspan="4">Объект төзү (реконструкцияләү, шул исәптән реставрацияләү элементлары белән, техник яңадан җиһазландыру) эшләрен үткәрүгә техник биремдә расланган капиталь төзелеш объектын төзүнең (реконструкцияләүнең, техник яңадан җиһазландыруның) иң чик кыйммәте, мең сум</td><td rowspan="4">Объект төзү (реконструкцияләү, шул исәптән реставрацияләү элементлары белән, техник яңадан җиһазландыру) эшләрен үткәрүгә техник бирем нигезендә төзелешнең норматив вакыты</td><td rowspan="4">Проект документларына дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсе реквизитлары (датасы, номеры) / дәүләт проект документлары бәяләмәсен алуның планлаштырыла торган датасы (ае, елы)</td><td rowspan="4">Дәүләт тарихи-мәдәни экспертиза бәяләмәсе реквизитлары (датасы, номеры) / дәүләт тарихи-мәдәни экспертиза бәяләмәсен алуның планлаштырыла торган датасы (ае, елы) (үткәрергә кирәк булганда күрсәтелә)</td><td rowspan="4">Дәүләт экология экспертизасы бәяләмәсе реквизитлары (датасы, номеры) / дәүләт экология экспертизасы бәяләмәсен алуның планлаштырыла торган датасы (ае, елы) (үткәрергә кирәк булганда күрсәтелә)</td><td rowspan="4">Капиталь төзелеш объектының смета кыйммәтен дөрес итеп билгеләү турында уңай бәяләмә реквизитлары (датасы, номеры) / капиталь төзелеш объектының смета кыйммәтен дөрес итеп билгеләү турында уңай бәяләмә алуның планлаштырыла торган датасы (ае, елы)</td></tr>
<tr><td colspan="3" rowspan="2">барысы</td><td colspan="12">шул исәптән</td></tr>
<tr><td colspan="3">федераль бюджет</td><td colspan="3">Россия Федерациясе субъекты бюджеты</td><td colspan="3">җирле бюджет</td><td colspan="3">бюджеттан тыш чыганаклар</td></tr>
<tr><td>20_ ел</td><td>20_ ел</td><td>20_ ел</td><td>20_ ел</td><td>20_ ел</td><td>20_ ел</td><td>20_ ел</td><td>20_ ел</td><td>20_ ел</td><td>20_ ел</td><td>20_ ел</td><td>20_ ел</td><td>20_ ел</td><td>20_ ел</td><td>20_ ел</td><td>территорияне планлаштыру буенча документларны раслау</td><td>җир кишәрлеген заказчыга бирү</td><td>проектлаштыруга контрактны раслау</td></tr>
<tr><td>1</td><td>2</td><td>3</td><td>4</td><td>5</td><td>6</td><td>7</td><td>8</td><td>9</td><td>10</td><td>11</td><td>12</td><td>13</td><td>14</td><td>15</td><td>16</td><td>17</td><td>18</td><td>19</td><td>20</td><td>21</td><td>22</td><td>23</td><td>24</td><td>25</td><td>26</td><td>27</td></tr>
<tr><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
</table>

<table>
<tr><td colspan="2" rowspan="2">Капиталь төзелеш объектының смета кыйммәтен дөрес итеп билгеләүне тикшерү турындагы бәяләмә нигезендә төзелеш кыйммәте, мең сум</td><td rowspan="4">Дәүләт (муниципаль) сатып алуны урнаштыру ысулы</td><td rowspan="4">Сатып алуларны үткәрү нәтиҗәсендә барлыкка килгән экономия, мең сум</td><td rowspan="4">Объект төзү (реконструкцияләү, шул исәптән реставрацияләү элементлары белән, техник яңадан җиһазландыру) эшләрен үткәрүгә контракт төзү датасы (контракт төзүнең планлаштырыла торган вакыты)</td><td colspan="14">Төзелгән контракт нигезендә төзелеш кыйммәте, мең сум</td></tr>
<tr><td colspan="6">барысы</td><td colspan="8">шул исәптән</td></tr>
<tr><td rowspan="2">бәяләрнең базислы дәрәҗәсе (2001 ел)</td><td rowspan="2">бәяләрнең агымдагы дәрәҗәсе</td><td colspan="3">бәяләрнең базислы дәрәҗәсе (2001 ел)</td><td colspan="3">бәяләрнең агымдагы дәрәҗәсе</td><td colspan="2">федераль бюджет</td><td colspan="2">Россия Федерациясе субъекты бюджеты</td><td colspan="2">җирле бюджет</td><td colspan="2">бюджеттан тыш чыганаклар</td></tr>
<tr><td>20_ ел</td><td>20_ ел</td><td>20_ ел</td><td>20_ ел</td><td>20_ ел</td><td>20_ ел</td><td>бәяләрнең базислы дәрәҗәсе (2001 ел)</td><td>бәяләрнең агымдагы дәрәҗәсе</td><td>бәяләрнең базислы дәрәҗәсе (2001 ел)</td><td>бәяләрнең агымдагы дәрәҗәсе</td><td>бәяләрнең базислы дәрәҗәсе (2001 ел)</td><td>бәяләрнең агымдагы дәрәҗәсе</td><td>бәяләрнең базислы дәрәҗәсе (2001 ел)</td><td>бәяләрнең агымдагы дәрәҗәсе</td></tr>
<tr><td>28</td><td>29</td><td>30</td><td>31</td><td>32</td><td>33</td><td>34</td><td>35</td><td>36</td><td>37</td><td>38</td><td>39</td><td>40</td><td>41</td><td>42</td><td>43</td><td>44</td><td>45</td><td>46</td></tr>
<tr><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
</table>

| Төзелеш | | | | Җиһаз | | | Хисап чоры ахырына капиталь төзелеш объектының техник әзерлеге, % | | | Дәүләт төзелеш күзәтчелеге органының төзелгән, реконструкция ясалган капиталь төзелеш объектының техник регламентлар һәм проект документлары таләпләренә, шул исәптән энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренә һәм капиталь төзелеш объектының кулланыла торган энергетика ресурсларын исәпкә алу җайланмалары белән тәэмин ителешенә карата таләпләргә туры килүкилмәве турындагы бәяләмәләр алуның планлаштырыла торган датасы (ае, елы) (алырга кирәк булганда тутырыла) | Төзелгән контракт нигезендә объектны файдалануга тапшыру вакыты |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| төзелешкә, реконструкциялә үгә рөхсәт алу | әзерлек эшләре башлану | төзелеш-монтаж эшләре | | сатып алу вакыты | урнаштыру вакыты | тапшыру вакыты | 20 _ ел | 20 _ ел | 20 _ ел | | |
| | | башы | ахыры | | | | | | | | |
| 47 | 48 | 49 | 50 | 51 | 52 | 53 | 54 | 55 | 56 | 57 | 58 |
| | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | |

Җитәкчесе ______________________ ____________________ ____________________________
(вазыйфасы) (имзасы) (имзасын тутырып язу)

Үтәүчесе ___________________ ___________________________ __________________
(вазыйфасы) (фамилиясе, исеме, атасының исеме) (телефоны)

20___ ел, «___»_______________

Сәнәгать (индустриаль) паркларының һәм технопаркларның җитештерү һәм инновация компанияләрен булдыру (үстерү) максатларында, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына җитештерү мәйданнарыннан һәм урыннарыннан ташламалы файдалана алу мөмкинлеге бирүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен сәнәгать (индустриаль) паркларының һәм (яки) технопаркларның идарә итүче компанияләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә 3 нче кушымта

Форма

20___ елның «___» ____________ хәленә карата
субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында хисап

Субсидия алучының исеме ______________________________________________________________

Дәвамлылыгы: еллык

| Т/с | Күрсәткеч исеме | Проект (чара) исеме | Гомумроссия үлчәү берәмлекләре классификаторы буенча үлчәү берәмлеге | | Күрсәткечнең план буенча мәгънәсе | Хисап көне хәленә карата күрсәткечнең ирешелгән мәгънәсе | Планны үтәү проценты | Тайпылу сәбәбе |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | исеме | коды | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| | | | | | | | | |

Җитәкчесе ____________________ ____________________ ____________________
(вазыйфасы) (имзасы) (имзасын тутырып язу)

Үтәүчесе ____________________ ____________________ ____________________
(вазыйфасы) (фамилиясе, исеме, атасының исеме) (телефоны)

20___ ел, «___»________________

_______________________________

Сәнәгать (индустриаль) паркларының һәм технопаркларның җитештерү һәм инновация компанияләрен булдыру (үстерү) максатларында, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына җитештерү мәйданнарыннан һәм урыннарыннан ташламалы файдалана алу мөмкинлеге бирүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен сәнәгать (индустриаль) паркларының һәм (яки) технопаркларның идарә итүче компанияләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә 4 нче кушымта

Форма

20___ елның «___» _______
аларның финанслар белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнар турында
хисап

Субсидия алучының исеме ___________________________________________________
Дәвамлылыгы: квартал, еллык
Үлчәү берәмлеге: сум (икенче унлык билгесенә кадәр төгәл итеп)

| Күрсәткеч исеме | Юл коды | Субсидияләрне тоту юнәлеше коды | Суммасы | |
|---|---|---|---|---|
| | | | хисап чоры | ел башыннан арта бара торган нәтиҗә белән |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Субсидиянең калган өлеше, барысы | 100 | - | | |
| шул исәптән:<br>ихтыяҗ булуы расланган | 110 | - | | |
| Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиешле | 120 | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| Акча керде, барысы | 200 | - | | |
| шул исәптән:<br>Татарстан Республикасы бюджетыннан | 210 | - | | |
| үткән елларның дебитор бурычы | 220 | - | | |
| Чыгымнар буенча түләүләр, барысы | 300 | | | |
| шул исәптән:<br>персоналга түләүләр, барысы | 310 | 0100 | | |
| шулардан: | | | | |
| эшләр башкару һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу, барысы | 320 | 0200 | | |
| шулардан: | | | | |
| җитештерү булмаган активларны, матди булмаган активларны, матди запасларны һәм төп чараларны сатып алу, барысы | 330 | 0300 | | |
| шулардан: | | | | |
| устав (җыелма) капиталына кертем, башка оешма мөлкәтенә кертемнәр сыйфатында акча күчерү (әгәр дә максатчан акча бирү тәртибен җайга сала торган норматив хокукый актлар нигезләмәләре белән аларны әлеге оешмага күчерү мөмкинлеге каралган булса), барысы | 340 | 0420 | | |
| шулардан: | | | | |
| счетлардан чыгу | 350 | 0610 | | |
| шулардан: | | | | |
| акчаны депозитларга, башка финанс инструментларына урнаштыру максатларында күчерү (әгәр дә федераль законнар белән максатчан чараларны мондый урнаштыру мөмкинлеге каралган булса), барысы | 360 | 0620 | | |
| шулардан: | | | | |
| Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр түләү, барысы | 370 | 0810 | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| шулардан: | | | | |
| башка түләүләр, барысы | 380 | 0820 | | |
| шулардан: | | | | |
| соңгы исәп-хисаплар буенча түләүләр, барысы | 390 | | | |
| шулардан: | | | | |
| Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылды, барысы | 400 | - | | |
| шул исәптән:<br>максатчан билгеләнеше буенча тотылмаган | 410 | - | | |
| штраф санкцияләре куллану нәтиҗәсендә | 420 | - | | |
| Хисап чоры ахырына субсидияләрнең калган өлеше, барысы | 500 | - | | |
| шул исәптән:<br>шул ук максатларга җибәрү таләп ителә | 510 | - | | |
| кире кайтарылырга тиеш | 520 | - | | |

Җитәкчесе __________________________ ________________________ __________________________________
(вазыйфасы) (имзасы) (имзасын тутырып язу)

Үтәүчесе ______________________ _________________________________ _____________________
(вазыйфасы) (фамилиясе, исеме, атасының исеме) (телефоны)

20___ ел, «___»_________________